

“Юлдаш” газетасында, Боек Ватан сугышында Жинүнен 80-еллык бәйрәменә әзерләнгәндә, якташ батырларыбыз турында сүз алып барабыз. Чираттагы язмабыз.
Паспортында язылганча Мещеров Джиган Хакимович (Ельниковский район, Акчеево, 1924-1980), 1942 елнын августында Приморье краенын Артём РВКсыннан чакырыла; ойрәнү полкында артиллерия разведчигы була. 1942 елнын декабреннән 1943 елнын февраленә кадәр 214 миномет полкы командиры, 1943 елнын февраленнән 1946 елнын декабренә кадәр 120 мм миномет командиры һәм 239 дивизионы разведчигы булып хезмәт итә.
Жиһан Хәким улы 1943 елнын апреленнән Волхов, 1943 елнын июленнән Брянск, 1943-1945 елнын июленнән Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында сугышкан. Курск дугасындагы сугышларда, Днепрны кичүдә, Киевны, Житомирны, Львовны азат итүдә катнаша. 1944 елнын 8 сентябрь - 28 октябрендә 1 нче УкрФ гаскәрләре Карпат-Дуклин операциясен үткәрәләр. Анда күрсәткән батырлыгы очен Мещеров «Батырлык очен» медале белән бүләкләнә. Жиденче сентябрьдә разведкада сугышып батырлык күрсәтә: 4 пулемет ноктасы, бер 75 мм орудие һәм дошманнын взводына кадәр пехота тупланышы табыла. Анын координаталары буенча дивизия аларны юк итә. Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләүгә Жиһан Хәким улы 1944 елнын 1 ноябрендә тәкъдим ителә. Бүләкләү кәгазеннән: «Карпат очен барган сугышларда 535 биеклек тирәсендәге күзәтү вакытында 8 ут ноктасын, шул исәптән 175 мм батарея, бер 105 мм батарея, 4 станоклы пулеметны ачыклаган. Нокталар укчы частьларга биеккә һожүм итәргә момкинлек бирмәгән. Ләкин Жиһан Хәким улы Мещеров, югарыда күрсәтелгән ут нокталарын ачыклап, батареяларга хәбәр итә һәм алар ут ачалар; дошман нокталары юк ителә».
Беренче УкрФ гаскәрләре Берлин һәм Прага операцияләрендә катнаша. Сержант Мещеров «Берлинны алган очен», «Праганы азат иткән очен» медальләре белән

бvләкләнгән.
Сугышта егетләр бик тиз олыгая һәм чыныга. 21 яшьлек сержант Мещеров биш сугышчан бvләк: орден һәм дvрт медаль белән бvләкләнә. Ә солдат бәхете дошманга каршы сугышкан барлык сугышларда да аны ташламаган: бер генә яра да, контузия дә алмыйча Жинvне каршылый безнен якташыбыз.
Сугыштан сонгы елларда Жиһан Хәким улы Мещеров туып vскән Кvгешендә - Акчеевосында яшәгән һәм бакыйлыкка кvчкән.

*Мәгълумат Ельники музее сайтыннан алынды*